Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык  авыл җирлеге Бутаиха  торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«28» ноябрь  2022 ел                                                                                                № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык  авыл җирлеге Бутаиха поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Бутаиха пос. территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан,  Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче:                                                В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы                                                     В.В. Рыжков